| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«05» сентябрь 2016 ел Олы Кайбыч ав. № 51

2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172 - ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – ФЗ-172), «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2016 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында»2015 елның 10 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карар Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырылырга һәм халыкка җиткерелергә тиеш: http://kaybici.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Н.Макаровка йөкләргә.

**Совет Рәисе,**
**муниципаль район Башлыгы** **А.И.Рәхмәтуллин**